Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлеге Советы

РЕШЕНИЕ КАРАР

10.12.2021 №47

«Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Ямбакты авыл җирлеге территориясендә төзеклэндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында» 2021елның 23 ноябрендәге №45 номерлы Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Ямбакты авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә ТР Спас муниципаль районының Ямбакты авыл җирлеге советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Ямбакты авыл җирлеге советы карарына «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Ямбакты муниципаль берәмлеге территориясендә төзеклэндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 23 ноябрендәге №45 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә.

1.1. 3 нче кушымтаның 2 пунктын редакциядә кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Ямбакты авыл җирлеге башлыгы И.Ә.Гәләветдинов.

СОВЕТ ЯМБУХТИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлеге Советының 2021 елның 10 декабрендәге 47 номерлы карарына кушымта

Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольнең индикатив күрсәткечләре исемлеге

1) хисап чорында контроль объектының мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары белән расланган параметрларга туры килүен ачыклау нигезендә үткәрелгән планнан тыш контроль (күзәтчелек) чаралары саны, яисә хисап чорында контроль объектының мондый параметрлардан читләшүе;

2) хисап чорында үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чараларның гомуми саны;

3) хисап чорында үткәрелгән һәр КНМ төре буенча үзара хезмәттәшлек белән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

4) хисап чорында дистанцион хезмәттәшлек чараларын кулланып үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

5) хисап чорында үткәрелгән мәҗбүри профилактик визитлар саны;

6) хисап чорында игълан ителгән мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтүләр саны;

7) хисап чорында мәҗбүри таләпләрне бозулар ачыкланган контроль (күзәтчелек) чаралары саны

8) хисап чорында административ хокук бозулар турында эшләр кузгатылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

9) контроль (күзәтчелек) чаралары нәтиҗәләре буенча хисап чорына салынган административ штрафлар суммасы;

10) хисап чорында тикшерү (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;

11) прокуратура органнарына контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында җибәрелгән гаризалар саны, алар буенча прокуратура органнары хисап чорында килешүдән баш тарткан;

12) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контроль объектларының гомуми саны;

13) хәвеф-хәтәр категорияләренә кертелгән исәпкә алынган контроль объектлары саны хисап чоры ахырына һәр риск категориясе буенча;

14) хисап чоры ахырына контрольдә тотылучы затларның исәпкә алынган саны;

15) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чаралары үткәрелгән исәпкә алынган контрольдә тотылучы затлар саны;

16) контроль (күзәтчелек) органнарының вазыйфаи затларының суд тәртибендә җибәрелгән карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү турында дәгъва гаризалары саны хисап чорында;

17) контроль (күзәтчелек) органнарының вазыйфаи затларының суд тәртибендә җибәрелгән карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү турында дәгъва гаризалары саны, алар буенча хисап чорында гариза бирелгән таләпләрне канәгатьләндерү турында Карар кабул ителгән.;

18) дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата таләпләрне тупас бозу белән үткәрелгән һәм нәтиҗәләре дөрес түгел дип танылды һәм (яисә) хисап чорында юкка чыгарылды торган контроль (күзәтчелек) чаралары.